УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ
ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ
СОСТОЯНИЕМ
САМОХОДНЫХ МАШИН И
ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ
БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ
ТЕХНИК ТОРЫШЫНА
КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

11.10.2017 Казан ш. 01-05/243-пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы
Дәүләт техника күзәтчелеге
идарәсе башлыгының
2017 елның 11 октябрендәге
01-05/243-пр номерлы боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында**
# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Бу Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) эшләү чорлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә (алга таба – Идарә) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс (алга таба – конкурс) дәүләт хезмәтенә карата тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Идарәдә конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Идарәдә конкурс Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгы (алга таба – Идарә башлыгы) карары буенча граждан хезмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә конкурс нигезендә биләнә торган вакант вазыйфа булган очракта игълан ителә.

1.4. Конкурс дәүләт хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүдә Идарәдә белгечләргә кытлык булуы ихтималына һәм Идарәнең үзендә булган кадрлар резервына ел саен уздырыла торган бәяләү нәтиҗәләре буенча Идарәнең оештыру-хокук эше буенча бүлеге тарафыннан оештырыла һәм уздырыла.

Конкурс Идарәнең конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә уздырыла.

1.5. Идарәдә дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы карый торган шул ук төркемдә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Татарстан Республикасы кадрлар резервына кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләре (гражданнар) турында белешмәләр алу өчен Идарә башлыгы Татарстан Республикасы Президенты каршында Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына гарызнамә җибәрә, анда Идарәнең структур бүлекчәсе һәм дәүләт хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча квалификация таләпләре күрсәтелеп, дәүләт хезмәтенең вакант вазыйфасы турында мәгълүматлар була.

1.6. Идарәдә вакант вазыйфаны биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

1) билгеле бер чорга биләнә торган «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләнгәндә;

2) вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

3) Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

4) граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.7. Идарәдә вакант вазыйфаны биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

1) алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Идарәнең хокукый акты белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

2) Идарә башлыгы карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.8. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

1) сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

2) граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

3) граждан хезмәте вазыйфаларын биләү буенча Идарәнең кадрлар резервын формалаштыру.

1.9. Конкурсларны үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

1) барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

2) һөнәри әһәмиятле объектив критерияләргә нигезләнеп кандидатларны бәяләү;

3) конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, граждан хезмәте вакант вазыйфалары (кадрлар резервына кертелү) таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

## 2. КОНКУРС КОМИССИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ АНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

2.1. Идарәдә конкурс уздыру өчен Идарә башлыгының боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясенең шәхси составы Идарә башлыгы боерыгы белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш уздыру көнен билгели һәм аның көн тәртибен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен мәгълүмат ягыннан тәэмин итә (гаризалар кабул итә, эшләр формалаштыра, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерә һ.б.).

2.3. Конкурс комиссиясе составына түбәндәгеләр керә: Идарә башлыгы урынбасары, Идарәнең оештыру-хокук эше бүлеге башлыгы, Идарәнең күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлеге башлыгы, Идарәнең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокук тәэминаты секторы җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты каршында Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе каршында Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Идарә башлыгы гарызнамәсе буенча бәйсез экспертлар - дәүләт хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр буларак, экспертларның шәхси белешмәләрен күрсәтмичә чакырыла торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре.

Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

Идарә каршында Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары конкурс комиссиясе составына кертү өчен Идарә башлыгы гарызнамәсе нигезендә Идарә каршында Иҗтимагый совет тарафыннан күрсәтелә.

2.4. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздырылганда, конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.5. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге булмаслык рәвештә төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.7. Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе Рәисенең тавышы хәл иткеч була.

2.8. Конкурста катнашучыларга карата конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

1) граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә аеруча туры килә, граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү өчен тәкъдим ителә;

2) граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә туры килми;

3) граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү өчен белдерелә торган таләпләргә туры килә, тиешле кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим ителә.

Дәүләт хезмәткәрләрен (гражданнарны) Идарәнең кадрлар резервына кертү дәүләт хезмәтенең алар билгеләнергә мөмкин булган вазыйфалар төркемен күрсәтеп башкарыла. Өстәмә рәвештә Идарәнең кадрлар резервына граждан хезмәткәрләре (гражданнар) шундагы вазыйфаларны биләү өчен кертелә торган структур бүлекчә аталышы һәм, Идарәнең кадрлар резервына кертелә торган дәүләт хезмәткәрләренең (гражданнарның) ризалыгы белән, дәүләт хезмәтенең алар билгеләнергә мөмкин булган кечерәк вазыйфалар төркеме күрсәтелә ала.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат юклыгында кабул ителә һәм түбәндәгеләр өчен нигез булып тора:

1) граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләү өчен;

2) дәүләт хезмәтенең вакант вазыйфасына билгеләүдән баш тарту өчен;

3) граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә конкурста җиңмәгән кандидатны Идарәнең кадрлар резервына кертү өчен.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиядә тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, анда Рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

## 3. КОНКУРСЛАРДА КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. Идарәдә граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.7 пункты белән күздә тотылган чорда әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.2. Гражданин (граждан хезмәткәре) граждан хезмәте вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмцте турында» Федераль законның 57 статьясының 1 өлешендәге 2 яисә 3 пунктында яки 59.1 статьясының 2 яисә 3 пунктында каралган дисциплинар түләттерүгә дучар ителгән граждан хезмәткәре конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Идарәдә граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатларга таләпләр Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турында законнары нигезендә билгеләнде.

3.4. Конкурста катнашу теләген белдергән Россия Федерациясе гражданины Идарәгә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхси гариза (шушы Нигезләмәгә 1 нче кушымта);

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы карары белән расланган формада тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосын (4x6 см) теркәп;

3) паспорт яки аны алмаштыра торган документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

4) һөнәри белем алуы турында, шулай ук гражданин ихтыярына карап – өстәмә белем алуы, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелүе турында документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

5) хезмәт кенәгәсенең (хезмәт итүгә (эшкә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яктан яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданинның эшен (хезмәт эшчәнлеген) раслый торган бүтән документлар;

6) гражданинда граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек

саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәпкә алу формасы);

7) Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган бүтән документлар.

3.5. Конкурста катнашу теләген белдергән, Идарәдә граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны Идарә башлыгы исеменә тапшыра.

Башка дәүләт органында уздырыла торган конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре шул дәүләт органына эшкә алучының вәкиле исеменә үзе тутырган, имзалаган һәм Идарәнең оештыру-хокук эше бүлеге тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы боерыгы белән расланган формадагы анкетаны, фотосын (4x6 см) теркәп тапшыра.

3.6. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Гражданин тарафыннан дәүләт органына тапшырылган белешмәләрнең дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш.

Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерүгә дучар була.

3.7. Конкурста катнашу өчен документлар, аларны кабул итү турында игълан Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итү буенча бердәм мәгълүмат системасында (алга таба – КС ИБМС) бастырылган көннән соң 21 календарь көне эчендә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почтадан җибәреп яисә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә тапшырыла.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, эшкә алучының вәкиле аларны карап тикшерү вакытын кичектерергә хокуклы.

## 4. КОНКУРСЛАРНЫ УЗДЫРУ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан

Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерияләре Идарәдә граждан хезмәте вазыйфаларына карата белдерелә торган квалификация таләпләре нигезендә әзерләнде.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләре үзгәртелергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә. Беренче этапта Идарәнең оештыру-хокук эше бүлеге тарафыннан түбәндәгеләр оештырыла:

1) Идарә сайтында һәм КС ИБМС системасында конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан урнаштырыла, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүматлар: граждан хезмәте вакант вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) аталышы, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, граждан хезмәтен үтү шартлары, Идарәдә граждан хезмәте вакант вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документларның һәм материалларның исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү дәвам итә торган чор, конкурс уздыруның күзалланган датасы, аның уздыру урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар, Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта да бастырылырга мөмкин.

2) кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә:

3) гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлеккә юнәлтелүе, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа Идарәнең оештыру-хокук эше бүлеге тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача рәвештә хәбәр ителә.

4.4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакант вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучы бу карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.4.4. Идарәдә граждан хезмәтенең бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидат булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу исә кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яисә вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурсның икенче этабын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында карар граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә дәгъва белдерүчеләр тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелгәннән соң, шулай ук, зарурлык булу очрагында, дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң, Идарә башлыгы тарафыннан кабул ителә.

Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документларны кабул итү тәмамланган көннән соңгы 30 календарь көне узганчы уздырыла, ә дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, конкурсның икенче этабын уздыру чоры эшкә алучының вәкиле тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында эшкә алучының вәкиле тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

Идарәнең оештыру-хокук эше бүлеге, конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көне узганчы, үзенең рәсми сайтында һәм КС ИБМС системасында аны уздыруның датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарның (граждан хезмәткәрләренең) (алга таба – кандидатлар) исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләмәләрне җибәрә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

2) Идарәдә граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карары кабул ителү.

4.4.7. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, граждан хезмәтен яки бүтән дәүләт граждан хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү

буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган методлардан файдаланып, шул исәптән Идарәдә граждан хезмәте вакант вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә тест һәм шәхси әңгәмә уздыру юлы белән тест уздыру һәм бүтән төрле конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

4.4.8. Идарәдә граждан хезмәтенең билгеле бер вакант вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына бирелә торган җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын граждан хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләргә таянып бәяли.

4.5. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары конкурсның икенче этап нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Кандидатлар тарафыннан алынган тавышлар саны, кандидатлар шундагы вазыйфага дәгъва кыла торган структур бүлекчә җитәкчесенең фикере Идарәдә граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат турында карар кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып тора.

4.7. Конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәте вакант вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары уздыру турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча Идарә башлыгының конкурста җиңүчене граждан хезмәте вакант вазыйфасына билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Конкурс комиссиясе граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү буенча конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны Идарәнең кадрлар резервына кертү турында тәкъдим холкына ия булган карар кабул итәргә хокуклы.

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2007 елның 27 апрелендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясының 1 өлешендәге 2 яисә 3 пункты яки 59.1 статьясының 2 яисә 3 пункты күздә тоткан дисциплинар шелтәсе булган граждан хезмәткәре Идарәнең кадрлар резервына кертелә алмый.

Кандидат ризалыгы белән, аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы карый торган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфасын биләү буенча кадрлар резервына кертү турында Идарә башлыгы боерыгы чыгарыла.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) Идарәнең кадрлар резервына кертү һәм аннан чыгару Идарә башлыгы боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә һәм ул кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә оештыру-хокук эше бүлеге тарафыннан Идарәнең кадрлар резервына кертелгән затлар реестрына һәм Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәткәренең (гражданинның) шәхси карточкасына тиешле язу кертелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) Идарәнең кадрлар резервына кертү турында яисә чыгару турында Идарәнең хокукый боерыгы күчермәсе Идарәнең оештыру-хокук эше бүлеге тарафыннан граждан хезмәткәренә (гражданинга) боерык Идарә башлыгы тарафыннан имзаланган көннән соң 14 эш көне эчендә тапшырыла (җибәрелә).

Граждан хезмәткәре (гражданин) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү Идарә боерыгы белән рәсмиләштерелә һәм килештерү өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук чорла Идарәнең рәсми сайтында һәм КС ИБМС системасында урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.11. Граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Идарә архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсе башлыгына

_____________________________________
(инициаллары, фамилиясе)

Гр.__________________________________
_____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Адресы:______________________________
_____________________________________

Тел.: ________________________________
E-mail:______________________________

## ГАРИЗА

Мине Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелеге идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашырга кертүегезне сорыйм:

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
(вазыйфаның һәм структур бүлекчәнең аталышы)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы указы белән, шул исәптән белдерелә торган квалификация таләпләре белән таныштым.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга карата рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасының уздырылуына риза.

Конкурс уздыру датасы һәм урыны турында электрон почта e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына sms-хәбәр ярдәмендә хәбәр алуга риза.

Гаризага түбәндәгеләрне терким: (теркәлә торган документларны санап чыгарга).

| _______________ | _______________ | __________________ |
|---|---|---|
| (дата) | (имза) | (тулы имза) |